Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының ундүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 август, 2021 ел № 97

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы белән, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тапу Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 16 декабрендәге 42 номерлы (2018 елның 29 гыйнварындагы 88/2 номерлы, 2018 елның 07 маендагы 93/7 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) элек кабул ителгән карарның үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов